**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Верхнеуслонского муниципального района**

422570, село Верхний Услон, ул. Чехова д. 18
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЮгарыОсланмуниципальрайонының**
**Башкарма комитет**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

422570, ЮгарыОсланавылы, Чехов ур., 18 нчейорт
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от ___________________ №_________

Муниципаль хезмәтләр бирүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, №210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 22 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 23.11.2010 ел, № 1367 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 14 ноябрендәге 738 номерлы карары нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Торак урыннарга мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм аңа тиңләштерелгән затлар аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм Дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидияләр бүлеп бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү буенча һәм авыл җирендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү таныклык бирү турында (6 нчы кушымта) муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1.7.Социаль наем шартнамәсе (7 нче кушымта) буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

1.8 Гражданнарга муниципаль милектәге торак урын бирү буенча социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта)

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 05 июнендәге 692 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Т.Н. Бурдина
Әзерләде һәм
бастырды
7 нөсхәдә